ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МЕНДЕЛЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЕНАБЕРДИНО АВЫЛ ҖИРЛЕГЕНЕҢ КУРАКОВО ТОРАК ПУНКТЫНДА
ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ

КАРАР

22 ноябрь 2024 ел № 2

2025 елда Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Енабердино авыл җирлегенең Кураково торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Енабердино авыл җирлегенең Кураково авылы гражданнар җыены
КАРАР КЫЛДЫ:

1. 2025 елда үзара салымны Менделеевск муниципаль районы Енабердино авыл җирлегенең Кураково авылында яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, махсус хәрби операциядә катнашучылардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, югары уку йортларының һәм урта махсус уку йортларының көндезге бүлеге студентларыннан тыш, 1000 сум күләмендә, I төркем инвалидлардан салымны 50% ка киметеп, 500 сум күләмендә кертергә.
2. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге ихтыяҗларга юнәлтергә:

1) Урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү, электр энергиясен тапшыру өчен билгеләнгән башка җайланмаларны ремонтлау (Кураково авылында яктырткычлар сатып алу һәм алыштыру).
2) Җир асты суларының табигый чыгу урыннарын (чишмәләрне) төзекләндерү (чишмәне ремонтлау, Кураково авылындагы чишмә территориясен төзекләндерү).

3) су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау (Кураково авылында насос сатып алу).

4) торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия автомобиль юлларын төзү ,ремонтлау, карап тоту (Кураково авылында юлларны кардан чистарту)»

3. Әлеге карарны Кураково авылында махсус җиһазландырылган мәгълүмат стендларына урнаштырып халыкка җиткерергә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга http://pravo.tatarstan.ru һәм Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында « Енабердино авыл җирлеге» бүлегендә урнаштырырга http://mendeleevsk.tatarstan.ru

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Енабердино  авыл җирлеге башлыгы                                                  Е.Ю.Скворцова